ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 25 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында” 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2014 елның 24 июлендәге 75-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 5; 2014, № 7) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Гражданның язма рәвештә бәян ителгән мөрәҗәгатендә мөрәҗәгать җибәрелә торган органның исеме йә тиешле вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, йә тиешле затның вазыйфасы, шулай ук тәкъдимнең, гаризаның яисә шикаятьнең асылын бәян итү, гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), җавап, мөрәҗәгатьне башка адреска юллау турындагы хәбәр җибәрелергә тиешле почта адресы яисә электрон почта адресы күрсәтелергә, шәхси имзасы һәм дата куелырга тиеш.”;

б) 3 өлештә “яисә җавап җибәрелергә тиешле урынның почта адресы” сүзләрен “яисә җавап җибәрелергә тиешле адрес (почта адресы яисә электрон почта адресы)” сүзләренә алмаштырырга;

в) 4 өлештә “почта адресы” сүзләрен “җавап җибәрелергә тиешле адрес” сүзләренә алмаштырырга;

г) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ өлеш өстәргә:

“$4^1$. Язмача мөрәҗәгать тексты тәкъдимнең, гаризаның яисә шикаятьнең асылын ачыкларга мөмкинлек бирмәгән очракта, мөрәҗәгатькә җавап бирелми һәм ул карау өчен тиешле компетенциясе булган органга яисә вазыйфаи затка җибәрелми, бу хакта мөрәҗәгатьне җибәргән гражданга мөрәҗәгатьне теркәгән көннән алып җиде көн эчендә хәбәр ителә.”;

д) түбәндәге эчтәлекле 5[1] өлеш өстәргә:

“5[1]. Органга яисә вазыйфаи затка кергән билгесез даирә затлары мәнфәгатьләренә кагыла торган тәкъдимнән, гаризадан яисә шикаятьтән гыйбарәт мөрәҗәгатькә, аерым алганда, билгесез даирә затларына карата чыгарылган суд карарына шикаять белдерелгән мөрәҗәгатькә җавап, шул исәптән суд карарына шикаять белдерү тәртибе аңлатылган җавап, әлеге Законның 9 статьясы таләпләрен үтәп, шушы органның “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылырга мөмкин. Органга яисә вазыйфаи затка җавабы шушы органның “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылган мәсьәлә буенча язмача мөрәҗәгать кергән очракта, аны теркәгән көннән алып җиде көн эчендә әлеге мөрәҗәгатьне җибәргән гражданга мөрәҗәгатьтә күтәрелгән мәсьәләгә “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җавап урнаштырылган рәсми сайтның электрон адресы хәбәр ителә, бу чакта суд карарына шикаять белдерелгән мөрәҗәгать кире кайтарылмый.”;

2) 7 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле 3[1] өлеш өстәргә:

“3[1]. Миграция өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын бозуның булырга мөмкин фактлары турында мәгълүмат булган язмача мөрәҗәгать аны теркәгән көннән алып биш көн эчендә, аны җибәргән гражданга мөрәҗәгатьне башка адреска юллау турында хәбәр итеп, федераль башкарма хакимиятнең миграция өлкәсендә хокук куллану функцияләрен, тикшереп тору, күзәтчелек итү һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтү функцияләрен гамәлгә ашыручы органының территориаль органына һәм Татарстан Республикасы Президентына җибәрелә, моңа әлеге Законның 4 статьясындагы 4 өлешендә күрсәтелгән очрак керми.”;

б) түбәндәге эчтәлекле 8 өлеш өстәргә:

“8. Суд карарына шикаять белдерелгән мөрәҗәгать аны теркәгән көннән алып җиде көн эчендә, шушы суд карарына шикаять бирү тәртибен аңлатып, мөрәҗәгатьне җибәргән гражданга кире кайтарыла.”;

3) 8 статьяга түбәндәге эчтәлекле 1[1] өлеш өстәргә:

“1[1]. Татарстан Республикасы Президентына кергән һәм миграция өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын бозуның булырга мөмкин фактлары турында мәгълүмат булган язмача мөрәҗәгать аны теркәгән көннән алып 20 көн эчендә карала.”;

4) 11 статьяда:

а) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4. Кабул итү урыны, кабул итү өчен билгеләнгән көннәр һәм сәгатьләр, гражданнарны кабул итүгә әзерлек өчен җаваплы вазыйфаи затларның элемтә телефоннары турындагы мәгълүмат гражданнар игътибарына “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәре һәм (яисә) массакүләм мәгълүмат чаралары аша җиткерелә. Күрсәтелгән мәгълүмат шулай ук органнар урнашкан биналарда һәркем керә алырлык урыннарда урнаштырыла.”;

б) 7 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“7. Шәхси кабул итү вакытында телдән бәян ителгән мөрәҗәгатьтәге фактларның һәм хәлләрнең булуы бәхәссез булса һәм аларны өстәмә тикшерү таләп ителмәсә, җавап, гражданның ризалыгы белән, кабул иткән зат тарафыннан телдән бирелергә мөмкин, бу хакта шәхси кабул итү карточкасына язып куела, ул мөрәҗәгать итүченең шәхси имзасы белән раслана. Граждан телдән бирелгән җавапка риза булмаса яисә мондый ризалык турында язманы имзасы белән раслаудан баш тартса, мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрнең асылы буенча язмача җавап бирелә.”;

в) 9 өлешнең 2 пунктында “Советлар Союзы Геройлары,” сүзләреннән соң “Дан орденының тулы кавалерлары,” сүзләрен өстәргә;

5) 15 статьяның 6 пунктында “очраклар керми,” сүзләреннән соң “ә әлеге Законның 4 статьясындагы $5^1$ өлешендә каралган очракта язмача җавап бирү турында үтенеч белән мөрәҗәгать итү нигезендә” сүзләрен өстәргә;

6) 19 статьяда:

а) 3 өлештә “мөрәҗәгатьнең” сүзеннән соң “электрон” сүзен төшереп калдырырга;

б) 4 өлештә “Электрон карточкадагы” сүзләрен “Мөрәҗәгать карточкасындагы” сүзләренә алмаштырырга;

7) 20 статьяда:

а) 2 өлештә “яшәү урыны адресын” сүзләрен “почта адресын яисә электрон почта адресын” сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлештә “адреслар” сүзеннән соң “, электрон почта адреслары” сүзләрен өстәргә;

8) 23 статьяның 4 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4. Гражданнарның кергән мөрәҗәгатьләренә анализ, шулай ук билгесез даирә затлары мәнфәгатьләренә кагылышлы әһәмиятлерәк мәсьәләләр буенча аңлатмалар органнар тарафыннан аларның “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларына урнаштырыла.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2018 ел, 14 май
№ 32-ТРЗ